ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Большая Красная, 15/9, г.
Казань,420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

Большая Красная ур., 15/9, Казан
ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ _112__

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«_22_» __09___ 2023ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2022 елның 19 маендагы 87 номерлы боерыгы белән расланган Төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (зарури таләпләрне контрольдә тотылучы зат тарафыннан үтәү турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлегенә) формасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең гамәлдәге норматив хокукый актларын законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (зарури таләпләрне контрольдә тотылучы зат тарафыннан үтәү турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеген) формасын раслау турында» 2022 елның 19 маендагы 87 номерлы боерыгы белән расланган Төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (зарури таләпләрне контрольдә тотылучы зат тарафыннан үтәү турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлегенә) формасына үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Н.Н.Воронская) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның гамәлдә булуы 2023 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге) мәсьәләләрен алып баручы башлык урынбасарына йөкләнә.

Җитәкче С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2022 елның 19 маендагы 87 номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2023 елның 22 сентябрендәге 112 номерлы боерыгы редакциясендә)

Форма

QR-код урыны

Төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе (зарури таләпләрне контрольдә тотылучы зат тарафыннан үтәү турында таныклый торган тикшерү сораулары исемлеге)

1. Федераль дәүләт контроле (күзәтчелеге), төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль төрләренең бердәм реестрына кертелгән контрольлек төре атамасы: төбәк дәүләт торак контроле (күзәтчелеге).
2. Контроль (күзәтчелек) органы атамасы: Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – ТР ДТИ).
3. Тикшерү кәгазе формасын раслау турында норматив хокукый акт реквизитлары: ТР ДТИ боерыгы 20___ елның ______________№ ______.
4. Контроль (күзәтчелек) чарасы төре _________________________________
5. Контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрелә торган контроль (күзәтчелек) объекты:_______________________________________
6. Контрольлектәге зат:_________________________________________

___________________________________________________________________________

(гражданинның яки шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм әтисенең исеме (булган очракта), салым түләүче буларак аның идентификация номеры һәм (яки) шәхси эшкуарның төп дәүләт теркәү номеры, гражданинның яки шәхси эшкуарның теркәлү адресы, юридик затның исеме,

___________________________________________________________________________

салым түләүче буларак аның идентификация номеры һәм (яки) төп дәүләт теркәү номеры, юридик затның (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерым структур бүлекчәләре) адресы

7. Тикшерү кәгазен тутырып, контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү урыны (урыннары): ____________________________________________
8. ТР ДТИ вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында ТР ДТИ карары реквизитлары:____________________
9. Контроль (күзәтчелек) чарасының исәпкә алу номеры: ______________
10. Контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрүче һәм тикшерү кәгазе тутыручы ТР ДТИ вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе һәм

инициаллары: ________________________________________________________________

11. Аларга бирелгән җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган зарури таләпләрнең эчтәлеген чагылдырган тикшерү сораулары исемлеге:

| № т/с | Сораулар исемлеге | Зарури таләпләрне билгели торган норматив хокукый актларның, аларның бүленеш берәмлекләрен күрсәтеп, белешмәләре | Сорауларга җаваплар | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | әйе | юк | кулла-нып бул-мый | |
| **1. Капиталь ремонт фондларын формалаштыруга карата таләпләрне үтәү** | | | | | | |
| 1.1. | Капиталь ремонт фондын формалаштыру өчен идарәче оешманы махсус счет хуҗасы итеп сайлап алу турында карар милекчеләрнең гомуми җыелышы тарафыннан кабул ителгәнме? | Россия Федерациясе Торак кодексының (алга таба – РФ Торак кодексы) 175 статьясындагы 2 өлеше | | | | |
| 1.2. | Махсус исәп хуҗасы буларак, идарәче оешма тарафыннан дәүләт торак күзәтчелеге органына тиешле күпфатирлы йортта (алга таба – КФЙ) биналарның милекчеләре тарафыннан сайлап алынган капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулы турында хәбәр, махсус счет ачу турында карарлар кабул итү турында әлеге КФЙ биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсе күчермәсен һәм банк белешмәләрен теркәп тапшырылганмы? | РФ Торак кодексының 172 статьясындагы 1 өлеше; «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы (алга таба – 52-ТРЗ номерлы ТР Законы); РФ Торак | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кодексының 46 статьясындагы 1 өлеше; Россия Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Күпфатирлы йортларда торак урын милекчеләренең гомуми җыелышлары беркетмәләрен рәсмиләштерүгә карата таләпләрне һәм Күпфатирлы йортларда торак урын милекчеләренең гомуми җыелышларындагы карарларны һәм беркетмәләрнең төп нөсхәләрен Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимиятенең торакка дәүләт күзәтчелеген башкаручы вәкаләтле органнарына җибәрү тәртибен раслау турында» 2019 елның 28 гыйнварындагы 44/пр номерлы боерыгы (алга таба – 44/пр номерлы боерык) | | | | |
| 1.3. | КФЙ биналары милекчеләренең капиталь ремонт фондын формалаштыру ысулын сайлау турында гомуми җыелышы беркетмәсендә әарури кушымталар бармы? | 44/пр номерлы боерык | | | | |
| 1.4. | Капиталь ремонт фондын махсус счетта формалаштыру ысулын сайлаганда милекчеләрнең гомуми җыелышы | РФ Торак кодексының 170 статьясының 4 | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | карары белән капиталь ремонт өчен айлык кертем күләме, махсус счет хуҗасы һәм махсус счет ачылачак кредит оешмасы билгеләнәме? | өлеше | | | | |
| 1.5. | Капиталь ремонт фондын махсус исәптә формалаштыру турында КФЙ биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы карары белән түбәндәгеләр билгеләнгәнме:<br>- түләү документларын, шул исәптән системаны кулланып, капиталь ремонт өчен кертемнәр түләүгә хезмәт күрсәтүгә вәкаләтле зат. Бу очракта әлеге пунктта күрсәтелгән вәкаләтле затны сайлау аның белән килештерү буенча гамәлгә ашырыла;<br>- түләү документларын бирү тәртибе;<br>- түләү документларын бирүгә бәйле чыгымнар күләме һәм әлеге хезмәтләр өчен түләү шартлары; | РФ Торак кодексының 175 статьясының $3^1$ өлеше | | | | |
| 1.6. | Идарәче оешма, махсус исәп хуҗасы буларак, дәүләт торак күзәтчелеге органына ай саен һәм хисап аеннан соң килүче айның 10 көненә кадәр, шул исәптән электрон рәвештә дә, капиталь ремонт өчен кертем сыйфатында исәпләнгән акчалар күләме турында белешмәләр, капиталь ремонтка кертемнәр сыйфатында кергән акчалар күләме турында белешмәләр, капиталь ремонт өчен махсус счеттан тотылган акчалар күләме турында белешмәләр, махсус счетта калган акчалар күләме турында белешмәләр, займ шартнамәсен төзү турында һәм (яки) мондый шартнамәләрнең расланган күчермәләрен теркшп, капиталь ремонт уздыруга кредит шартнамәсе төзү турында белешмәләр тапшырамы? | РФ Торак кодексының 172 статьясындагы 3 өлеше;<br>52-ТРЗ номерлы ТР Законының 12 статьясы | | | | |
| 1.7. | Идарәче оешма, махсус счет хуҗасы буларак, капиталь ремонт фондына кертемнәр буенча бурычларны түләттерүне башкарамы? | РФ Торак кодексының 173 статьясының 9 өлеше | | | | |
| 1.8. | Бина милекчеләренең гомуми җыелышы карарларында түбәндәгеләр билгеләнгән яисә расланганмы:<br>- капиталь ремонт буенча күрсәтелә торган хезмәтләр һәм (яки) башкарыла торган эшләр исемлеге;<br>- капиталь ремонт буенча күрсәтелә | РФ Торак кодексының 189 статьясындагы $5^1$ өлеше | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | торган хезмәтләр һәм (яки) башкарыла торган эшләр исемлеге;<br>- капиталь ремонт үткәрү вакытлары;<br>- капиталь ремонтны финанслау чыганаклары;<br>- КФЙ биналарның барлык милекчеләре исеменнән күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне кабул итүдә катнашырга, шул исәптән тиешле актларга кул куярга вәкаләтле зат; | | | | | |
| 1.9. | КФЙ биналарның милекчеләренең гомуми җыелышының КФЙ биналарның милекчеләренең әлеге җыелышта катнашкан тавышларның гомуми санының илледән артык тавыш белән кабул ителгән капиталь ремонтны формалаштыру ысулын сайлау турында карары бармы? | РФ Торак кодексының 46 статьясындагы 1 өлеше | | | | |
| 1.10. | Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасына, Капиталь ремонт программасын формалаштыру һәм дәүләт программасы үтәлешенә мониторинг һәм торак фонды объектлары торышына мониторинг дәүләт мәгълүмат системасына, торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасына капиталь ремонт фондын формалаштыру турында хокукый актларда билгеләнгән мәгълүмат кертелгәнме? | «Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2014 елның 21 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба –209-ФЗ номерлы федераль закон); Россия Федерациясе Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы белән Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | мәгълүмат урнаштыру составын, срокларын һәм ешлыгын раслау турында» 2016 елның 29 февралендәге 74 һәм 114/пр номерлы уртак боерыгы (алга таба – № 74/№114/пр боерык) | | | | |
| **2. КФЙ белән идарә итүче, КФЙ гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүче һәм (яки) эшләр башкаручы юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлегенә карата таләпләр үтәлеше.** | | | | | | |
| 2.1. | КФЙ биналарның милекчеләренең гомуми җыелышында КФЙ белән идарә итү максатларында ТМШ/ТК/ТТК төзү турында мондый йорттагы биналарның милекчеләренең гомуми саныннан илледән артык тавыш белән карар кабул ителгәнме? | РФ Торак кодексының 136 статьясындагы 1 өлеше | | | | |
| 2.2. | КФЙ белән идарә итү максатларында ТМШ/ТК/ТТК төзү турында карар кабул итү өчен тавыш биргән КФЙ биналарының барлык милекчеләре белән гомуми җыелыш беркетмәсенә кул куелганмы? | РФ Торак кодексының 136 статьясындагы $1^1$ өлеше | | | | |
| 2.3. | Устав нигезләмәләре торак законнары таләпләренә каршы килмиме? | РФ Торак кодексының 136 статьясындагы 2 өлеше | | | | |
| 2.4. | ТМШ/ТК/ТТК әгъзаларының гомуми җыелышында ТМШ/ТК/ТТК уставында каралган очракларда, идарә әгъзалары арасыннан ТМШ/ТК/ТТК идарә әгъзаларын, ревизия комиссиясе әгъзаларын (ревизор) һәм, ТМШ/ТК/ТТК уставында каралган очракларда, идарә әгъзалары арасыннан идарә рәисен сайлау турында карар кабул итү тәртибе үтәлгәнме? | РФ Торак кодексының 145 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты, 146, 147, 150 статьялары | | | | |
| 2.5. | ТМШ/ТК/ТТК ТР ДТИ адресына өч ел дәвамында саклау өчен КФЙ биналарның милекчеләренең гомуми | РФ Торак кодексының 46 статьясындагы $1^1$ | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | җыелышлары беркетмәләренең төп нөсхәләрен җибәрү срокларын үтиме? | пунктчасы | | | | |
| 2.6. | ТМШ/ТК/ТТК тарафыннан ТМШ/ТК/ТТК әгъзалары реестры алып барыламы, андагы мәгълүматлар дөрес һәм актуальме? | РФ Торак кодексының 143 статьясындагы 1, 3, 4, 6 өлешләр, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2013 елның 15 маендагы 416 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру кагыйдәләренең 4 пунктындагы «б» пунктчасы (алга таба – 416 номерлы кагыйдәләр) | | | | |
| 2.7. | ТМШ агымдагы елның беренче кварталы дәвамында әлеге реестрның күчермәләрен ТР ДТИ адресына юллау бурычын үтиме? | РФ Торак кодексының 138 статьясындагы 9 пункты | | | | |
| 2.8. | ТМШ/ТК/ТТК тарафыннан КФЙ биналарны яллаучылар, шулай ук КФЙ биналарның милекчеләренең гомуми мөлкәтен кулланучы затлар турында мәгълүмат җыю, яңарту һәм саклау, шулай ук КФЙ биналарның милекчеләре реестрын алып бару гамәлгә ашырыламы? | РФ Торак кодексының 45 статьясының $3^1$ өлеше, 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктның «б» пунктчасы, 19, 20, 22 пунктлары | | | | |
| 2.9. | ТМШ/ТК/ТТК тарафыннан КФЙ биналарның милекчеләренең гомуми мөлкәтенә уртак милек хокукындагы өлешләре турында мәгълүматларны җыю, яңарту һәм саклау гамәлгә | РФ Торак кодексының 45 статьясының $3^1$ өлеше, 416 номерлы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | ашырыламы? | кагыйдәләрнең 4 пунктның «б» пунктчасы, 19, 20, 22 пунктлары | | | | |
| 2.10. | ТМШ/ТК/ТТК тарафыннан ТМШ/ТК/ТТК әгъзаларына, ТМШ/ТК/ТТК әгъзалары булып тормаган КФЙ биналарның милекчеләренә торак законнарында билгеләнгән документлар белән танышып чыгу хокукы биреләме? | РФ Торак кодексының $143^1$ статьясының 3 өлеше | | | | |
| 2.11. | Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертү бурычын үтәмәүчеләргә карата дәгъва һәм шикаять эше алып барыламы? | 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктындагы «д» пунктчасы | | | | |
| 2.12. | Торак урыннары милекчеләренә (файдаланучыларга) мәгълүмат бирүгә торак законнарында билгеләнгән таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 165 статьясындагы 2 өлеше, 416 номерлы Кагыйдәләрнең VIII бүлеге | | | | |
| **3. КФЙ биналарның милекчеләренә һәм файдаланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә карата таләпләр үтәлеше** | | | | | | |
| 3.1. | Җылылык буенча коммуналь хезмәт күрсәтүгә зарури таләпләр үтәләме? | Коммуналь хезмәтләр өчен түләү исәпләү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 06.05.2011 ел, №354 карары белән расланган Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең (алга таба – 354 номерлы кагыйдәләр) 31 пунктының «а» пунктчасы | | | | |
| 3.2. | Кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтүгә карата | 354 номерлы кагыйдәләрнең 31 | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | зарури таләпләр үтәләме? | пунктындагы «а» пунктчасы | | | | |
| 3.3. | Салкын су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтүгә карата зарури таләпләр үтәләме? | 354 номерлы кагыйдәләрнең 31 пунктындагы «а» пунктчасы | | | | |
| 3.4. | Электр белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтүгә карата зарури таләпләр үтәләме? | 354 номерлы кагыйдәләрнең 31 пунктындагы «а» пунктчасы | | | | |
| 3.5. | Газ белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтүгә карата зарури таләпләр үтәләме? | 354 номерлы кагыйдәләрнең 31 пунктындагы «а» пунктчасы | | | | |
| **4. КФЙ белән идарә итү, гомуми мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару тиешле сыйфатта башкарылмаган очракта һәм (яки) билгеләнгән вакыт озынлыгын арттырып җибәрә торган тәнәфесләр белән гамәлгә ашырылган очракта, торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләренең үтәлеше** | | | | | | |
| 4.1. | Хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару тиешле сыйфатта башкарылмаган очракта һәм (яки) билгеләнгән вакыт озынлыгын арттырып җибәрә торган тәнәфесләр белән гамәлгә ашырылган очракта, торак урынны карап тоту өчен түләү күләме үзгәртеләме (киметеләме)? | РФ Торак кодексының 156 статьясының 10 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тоту һәм тиешенчә ремонтлау буенча сыйфатсыз хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару очрагында яисә хезмәтләрне билгеләнгән вакыт озынлыгын артып киткән өзеклекләр белән күрсәтү очрагында торак | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләренең 6 пункты | | | | |
| **5. КФЙ гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен үтәү** | | | | | | |
| 5.1. | Елның җылы чорында йорт яны территориясен карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-$1^2$, $2^1$-$2^3$ өлешләре; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту кагыйдәләренең 11 пунктының «з» пунктчасы (алга таба – 491 номерлы кагыйдәләр); 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь комплекс буенча дәүләт комитетының 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары белән расланган Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләре һәм нормаларының 3.5.9, 3.8.3, 3.9.1 пунктлары (алга таба – 170 номерлы ПиН | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кагыйдәләре) | | | | |
| 5.2. | Елның салкын чорында йорт яны территориясен карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-$1^2$, $2^1$-$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктындагы «г» пунктчасы; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 3 апрелендәге 290 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тоту өчен кирәкле хезмәтләрнең һәм эшләрнең минималь исемлегенең 24 пункты (алга таба – Минималь исемлек); 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктындагы «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 3.6.4, 3.6.21 пунктлары | | | | |
| 5.3. | Сыек көнкүреш калдыклары белән эш итү өлкәсендә таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-$1^2$, $2^1$ -$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «д»; «з» пунктчалары; Минималь исемлекнең 26 пункты; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кагыйдәләренең 3.7.1, 3.7.8-3.7.13 пунктлары | | | | |
| 5.4. | КФЙ башка гомуми мөлкәтне карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-$1^2$, $2^1$ -$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «з» пунктчасы; Минималь исемлекнең 23 пункты; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 3.2.2, 3.2.7, 4.8.14 пунктлары | | | | |
| 5.5. | Подвал бүлмәләрен карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-$1^2$; $2^1$ -$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «а»; «з» пунктчалары; Минималь исемлекнең 2 пункты; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 3.4.1-3.4.4, 4.1.1, 4.1.3, 4.1.10, 4.1.15 пунктлары | | | | |
| 5.6. | КФЙ диварларын, фасадларын карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1 - $1^2$, $2^1$-$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «а», «з» пунктчалары; | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Минималь исемлекнең 3 пункты; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 4.2- 4.2.2.4, 4.2.4.9, 4.10.2.1 пунктлары | | | | |
| 5.7. | КФЙ капламаларын карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-$1^2$, $2^1$-$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «а», «з» пунктчалары; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 4.3.1-4.3.7 пунктлары | | | | |
| 5.8. | КФЙ түбәләрен карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1 - $1^2$, $2^1$ - $2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «а», «з» пунктчалары; Минималь исемлекнең 7 пункты; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 4.6.1.1, 4.10.2.1 пунктлары | | | | |
| 5.9. | КФЙ баскыч урыннарын карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1 - | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | $1^2$, $2^1$ -$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «а», «з» пунктчалары; Минималь исемлекнең 8 пункты; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 3.2.2, 4.8.1, 4.8.3, 4.8.4, 4.8.7, 4.8.13 пунктлары | | | | |
| 5.10. | КФЙ гомуми мөлкәт составына керүче тәрәзәләрне һәм ишекләрне карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1 - $1^2$, $2^1$ -$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «а», «з» пунктчалары; Минималь исемлекнең 12 пункты; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 4.4.1, 4.4.3, 4.4.4 - 4.4.6, 4.4.8, 4.4.12, 4.4.16 пунктлары | | | | |
| 5.11. | КФЙ җылылык системасын карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-$1^2$, $2^1$ -$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «а», «в», «з» пунктчалары; Минималь исемлекнең 17 пункты; 416 номерлы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 5.1.1-5.1.3 пунктлары | | | | |
| 5.12. | КФЙ кайнар су белән тәэмин итү системаларын карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-$1^2$, $2^1$ -$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «а», «в», «з» пунктчалары; Минималь исемлекнең 17, 18 пунктлары; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 5.1.1 – 5.1.3, 5.3.6 пунктлары | | | | |
| 5.13. | КФЙ салкын су белән тәэмин итү системаларын карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-$1^2$, $2^1$ -$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «а», «з» пунктчалары; Минималь исемлекнең 17, 18 пунктлары; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы | | | | |
| 5.14. | КФЙ ташландык су агызу системаларын карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-$1^2$, $2^1$ -$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «з» пунктчасы; Минималь | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исемлекнең 18 пункты; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 5.8.1 - 5.8.4 пунктлары | | | | |
| 5.15. | КФЙ электр белән тәэмин итү системаларын карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1 – $1^2$, $2^1$ - $2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «а», «з» пунктчалары; Минималь исемлекнең 20 пункты | | | | |
| 5.16. | КФЙ вентиляция һәм төтенне бетерү системаларын карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1 – $1^2$, $2^1$ –$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «а», «з» пунктчалары; Минималь исемлекнең 15 пункты; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 5.7.2, 5.7.3, 5.7.9 пунктлары | | | | |
| 5.17. | КФЙ янгынга каршы, төтенгә каршы саклык буенча автоматлаштырылган вентиляция системаларын карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1 – $1^2$, $2^1$ –$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «а», «з», «е» | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | пунктчалары; Минималь исемлекнең 15 пункты; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 3.2.1, 5.6.2 пунктлары | | | | |
| 5.18. | КФЙ лифт җиһазларын карап тоту буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1 – $1^2$, $2^1$ –$2^3$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «з» пунктчасы; Минималь исемлекнең 22 пункты; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 2.7.5, 5.10.2 пунктлары | | | | |
| 5.19. | КФЙ чүп үткәргечләрен карап тоту буенча зарури таләпләр үтәләме? | РФ ТК 161 статьясының 1-$1^2$; $2^1$-$2^3$ өлешләре; 491 номерлы Кагыйдәләрнең 11 пунктының «з» пунктчасы; Минималь исемлекнең 14, $26^1$ пунктлары; 416 номерлы Кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 354 номерлы Кагыйдәләрнең $148^{22}$ пунктының «в» пунктчасы; 170 номерлы ПиН 5.9.10, 5.9.16, | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 5.9.17, 5.9.19, 5.9.20 пунктлары | | | | |
| 5.20. | Авария-диспетчерлык хезмәтен оештыру буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-1$^{2}$ өлешләре; Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 3 апрелендәге 290 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләрне күрсәтү һәм эшләр башкару кагыйдәләренең 6 пунктының «а» пунктчасы; 170 номерлы ПиН 2.2.3, 2.7.1, 2.7.3 пунктлары | | | | |
| 5.21. | Торак фондын сезонлы эксплуатацияләүгә әзерләү буенча таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-1$^{2}$, 2$^{1}$ -2$^{3}$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «з» пунктчасы; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 170 номерлы ПиН кагыйдәләренең 2.6.2 пункты | | | | |
| 5.22. | Торак бина өчен түләү, шул исәптән торак бинаны карап тоту өчен түләү, КФЙ белән идарә итү, КФЙ гомуми мөлкәтне карап тоту һәм агымдагы ремонт өчен түләү күләме дөрес кулланыламы? | РФ Торак кодексының 36 статьясындагы 1 өлеше, 37 статьясындагы 1 өлеше, 156 статьясы, 158 статьясындагы 4 өлеше | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 5.23. | Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне кулланганда һәм карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләүне исәпләү күмәк (гомумйорт) һәм индивидуаль исәпкә алу приборлары күрсәткечләреннән чыгып дөрес гамәлгә ашырыламы: | | | | | |
| | - электр энергиясен куллану буенча; | РФ Торак кодексының 156 статьясының $9^2$, $9^3$ өлешләре | | | | |
| | салкын су белән тәэмин итү буенча; | | | | | |
| | - кайнар су буенча. | | | | | |
| 5.24. | Законда билгеләнгән очракларда күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне кулланганда һәм карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләүне исәпләгәндә күмәк (гомумйорт) һәм индивидуаль исәпкә алу приборлары күрсәткечләре дөрес кулланыламы: | | | | | |
| | - электр энергиясен куллану буенча; | РФ Торак кодексының 156 статьясының $9^2$, $9^3$ өлешләре | | | | |
| | салкын су белән тәэмин итү буенча; | | | | | |
| | - кайнар су буенча. | | | | | |
| 5.25. | Законда билгеләнгән очракларда КФЙ гомуми мөлкәтне кулланганда һәм карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләүне хисаплаганда вәкаләтле орган тарафыннан расланган нормативлар дөрес кулланыламы: | | | | | |
| | - электр энергиясен куллану буенча; | РФ Торак кодексының 156 статьясының $9^2$, $9^3$ өлешләре | | | | |
| | салкын су белән тәэмин итү буенча; | | | | | |
| | - кайнар су буенча. | | | | | |
| 5.26. | КФЙ гомуми мөлкәтне кулланганда һәм карап тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләүне исәпләгәндә торак һәм торак булмаган (күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә карамый торган) биналар, уртак файдаланудагы урыннар мәйданнары дөрес файдаланыламы: | | | | | |
| | - электр энергиясен куллану буенча; | РФ Торак кодексының 36 статьясындагы 1 өлеше, 37 статьясындагы 1 өлеше, 156 статьясы | | | | |
| | салкын су белән тәэмин итү буенча; | | | | | |
| | - кайнар су буенча. | | | | | |
| **6. КФЙ һәм торак йортларда биналарның милекчеләренә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү, туктатып тору һәм чикләү кагыйдәләрен үтәү** | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.1. | Коммуналь хезмәт күрсәтүне чикләү яки туктатып тору процедурасы башланыр алдыннан зарури таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1 өлеше; 354 номерлы кагыйдәләрнең 114-122 пунктлары | | | | |
| 6.2. | Коммуналь хезмәт өчен түләүне исәпләү тәртибе саклана мы: | | | | | |
| 6.2.1 | - электр белән тәэмин итү буенча | 354 номерлы кагыйдәләрнең VI бүлеге | | | | |
| 6.2.2 | - салкын су белән тәэмин итү буенча | | | | | |
| 6.2.3 | - кайнар су белән тәэмин итү буенча | | | | | |
| 6.2.4. | - ташландык су агызу буенча | | | | | |
| 6.2.5. | - ягып җылыту буенча | | | | | |
| 6.2.6. | - газ белән тәэмин итү буенча | | | | | |
| 6.2.7 | - каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча | 354 номерлы кагыйдәләрнең $148^{27}$ – $148^{37}$ пунктлары | | | | |
| 6.3. | Вәкаләтле орган тарафыннан коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә кулланыла торган коммуналь ресурсларга билгеләнгән тарифлар дөрес кулланыламы: | | | | | |
| | - электр белән тәэмин итү буенча | РФ Торак кодексының 157 статьясының 2 өлеше | | | | |
| | - салкын су белән тәэмин итү буенча | | | | | |
| | - кайнар су белән тәэмин итү буенча | | | | | |
| | - ташландык су агызу буенча | | | | | |
| | - ягып җылыту буенча | | | | | |
| | - газ белән тәэмин итү буенча | | | | | |
| | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча коммуналь хезмәт күрсәтүгә бәя дөрес кулланыламы? | РФ Торак кодексының 157 статьясындагы 2 өлеше, 354 номерлы кагыйдәләрнең $148^{28}$ пункты | | | | |
| 6.4. | Вәкаләтле орган тарафыннан расланган коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә кулланыла торган коммуналь ресурсларга нормативлар дөрес кулланыламы: | | | | | |
| | - электр белән тәэмин итү буенча | РФ Торак кодексының 157 статьясындагы 1 өлеше | | | | |
| | - салкын су белән тәэмин итү буенча | | | | | |
| | - кайнар су белән тәэмин итү буенча | | | | | |
| | - ташландык су агызу буенча | | | | | |
| | - ягып җылыту буенча | | | | | |
| | - газ белән тәэмин итү буенча | | | | | |
| | Каты коммуналь калдыклар белән эш | РФ Торак | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | итү буенча вәкаләтле орган тарафыннан расланган коммуналь хезмәт өчен түләүне исәпләгәндә каты коммуналь калдыклар туплау нормативы дөрес кулланыламы? | кодексының 157 статьясындагы 1 өлеше, 354 номерлы кагыйдәләрнең $148^{30}$ пунктының беренче абзацы, $148^{31}$ пунктының беренче абзацы; $148^{32}$ пункты | | | | |
| 6.5. | Коммуналь хезмәтләр өчен түләү хисаплаганда куллану нормативына артыклык коэффициентлары хаклы нигездә кулланыламы | РФ Торак кодексының 157 статьясындагы 1 өлеше, 354 номерлы кагыйдәләрнең 42 пунктының өченче абзацы, 60 пунктының беренче абзацы, $60^{1}$ пунктының өченче абзацы, $60^{3}$ пункты, 62 пунктының өченче абзацы, $81^{11}$ пунктының алтынчы абзацы, $85^{3}$ пункты | | | | |
| 6.6. | Коммуналь хезмәтләр өчен түләүне исәпләгәндә коммуналь ресурсны индивидуаль исәпкә алу приборы күрсәткечләре дөрес кулланыламы: | | | | | |
| | - электр белән тәэмин итү буенча | РФ Торак кодексының 157 статьясындагы 1 өлеше | | | | |
| | - салкын су белән тәэмин итү буенча | | | | | |
| | - кайнар су белән тәэмин итү буенча | | | | | |
| | - ташландык су агызу буенча | | | | | |
| | - ягып җылыту буенча | | | | | |
| | - газ белән тәэмин итү буенча | | | | | |
| 6.7. | КФЙ мондый исәпкә алу җайланмасы белән җиһазланган очракта, җылылык энергиясен күмәк (гомумйорт) исәпкә алу приборы күрсәткече җылылык буенча коммуналь хезмәт өчен түләүне исәпләгәндә дөрес кулланыламы? | 354 номерлы кагыйдәләрнең $42^{1}$ пункты | | | | |
| 6.8. | Торак һәм торак булмаган (КФЙ гомуми мөлкәткә карамаган) биналарның, уртак кулланылыштагы урыннарның мәйданы җылыту буенча коммуналь хезмәт өчен түләүне исәпләгәндә дөрес кулланыламы? | 354 номерлы кагыйдәләрнең $42^{1}$ пункты | | | | |
| 6.9. | Били торган торак урынында | 354 номерлы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | кулланучылар вакытлыча булмаган чорда коммуналь хезмәтләрнең аерым төрләре өчен түләү күләмен яңадан исәпләү тәртибе үтәләме? | кагыйдәләрнең VIII бүлеге | | | | |
| 6.10. | Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү документына карата билгеләнгән таләпләр үтәләме? | 354 номерлы кагыйдәләрнең $69^{1}$ пункты | | | | |
| 6.11. | Коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүне чикләү буенча билгеләнгән таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының $157^{1}$ статьясының 1 өлеше | | | | |
| 6.12. | Торак урыннар милекчеләренә (алардан файдаланучыларга) коммуналь хезмәтләр өчен түләү хисаплауга кагылышлы мәгълүмат бирүгә торак законнарында билгеләнгән таләпләр үтәләме? | РФ Торак кодексының 165 статьясындагы 2 өлеше, 354 номерлы кагыйдәләрнең 31 пункты, $148^{22}$ пункты | | | | |
| 6.13. | Коммуналь хезмәтләрне тиешле сыйфатта күрсәтмәгән очракта һәм (яки) билгеләнгән вакыт озынлыкларын арттырып җибәргән өзеклекләр белән күрсәткән очракта коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен билгеләнгән тәртиптә үзгәртү (киметү) башкарыламы? | 354 номерлы кагыйдәләрнең IX бүлеге | | | | |
| **7. Энергия нәтиҗәлелеге һәм КФЙ биналарын һәм торак йортларны энергия ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин итү таләпләрен үтәү** | | | | | | |
| 7.1. | Торак фондта энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча зарури таләпләр үтәләме (энергия-саклау буенча чаралар турында милекчеләргә җиткерү)? | РФ Торак кодексының 161 статьясының $1\text{-}1^{2}$, $2^{1}\text{-}2^{2}$ өлешләре; 416 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «и» пунктчасы; «Энергияне саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261- | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 261-ФЗ номерлы федераль закон) 12 статьясының 7 өлеше | | | | |
| 7.2. | Энергетика ресурслары өчен исәп-хисап ясаганда кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алуны һәм кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу приборларын куллануны тәэмин итүгә карата зарури таләпләр үтәләме (гомумйорт приборлары, аларны эксплуатацияләүгә кертү актларының булуы)? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-$1^2$, $2^1$-$2^2$ өлешләре; 491 номерлы Кагыйдәләрнең 11 пунктының «и», «к» пунктчалары; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы; 261-ФЗ номерлы федераль законның 13 статьясының 5 пункты | | | | |
| 7.3. | Гомуми мөлкәткә карата зарури булган, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган чаралар исемлегенә кертелгән энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру чаралары үткәреләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 1-$1^2$, 2 $^1$-$2^2$ өлешләре; 491 номерлы кагыйдәләрнең 11 пунктының «и» пунктчасы; 416 номерлы кагыйдәләрнең 4 пунктының «д» пунктчасы | | | | |
| **8. КФЙ белән идарә итү буенча эшчәнлек алып баручы затлар тарафыннан системада мәгълүмат урнаштыру тәртибенә карата таләпләр үтәлеше** | | | | | | |
| 8.1. | КФЙ белән идарә итү буенча идарәче оешмаларның эшчәнлеге турында мәгълүматны урнаштыру буенча зарури таләпләр үтәләме? | № 74/№114/пр боерыкның 10 бүлеге | | | | |
| **9. КФЙ инвалидлар өчен биналардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә карата таләпләр үтәлеше** | | | | | | |
| 9.1 | КФЙ гомуми мөлкәтне инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру мәсьәләләрен хәл иткәндә күпфатирлы йортлардагы биналарның милекчеләренең гомуми җыелышы | РФ Торак кодексының 36 статьясының 4.1 пункты | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | карары булуына (булмавына) карата таләпләр үтәләме? | | | | | |
| **10. Йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын куркынычсыз эксплуатацияләүгә һәм техник хезмәт күрсәтүгә мәҗбүри таләпләрне, шулай ук күпфатирлы йортта гомуми мөлкәткә караган вентиляция һәм төтен каналларын тотуга таләпләрне үтәве дә тора.** | | | | | | |
| 0.1. | Күпфатирлы йортта йорт эчендәге газ җиһазларын куркынычсыз куллану һәм карап тоту таләпләре үтәләме (әгәр мондый җиһазлар урнаштырылган булса)? | РФ Торак кодексының 161 статьясының $1^1$ өлешендәге $2^1$ пункты | | | | |
| 0.2. | Коммуналь газ белән тәэмин итү хезмәте күрсәткәндә йорт эчендәге һәм фатир эчендәге газ җиһазларын кулланганда һәм саклаганда газны куллану кагыйдәләре үтәләме? | РФ Торак кодексының 161 статьясының 22 өлеше | | | | |
| 0.3. | ТМШ-ТК-ТТК уставында «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән махсуслаштырылган һәм йорт эчендәге һәм (яисә) фатир эчендәге газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау эшчәнлеген гамәлгә ашыруга махсус хокук бирелгән оешма белән күпфатирлы йортта йорт эчендәге газ җиһазларына (мондый җиһазлар урнаштырылган булса) техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау турында шартнамә төзү бурычы каралганмы? | РФ Торак кодексының 113 статьясының $1^2$ өлеше, 135 статьясының $2^2$ өлеше. | | | | |

____________________________________
(тикшерү кәгазен тутыру датасы)

Контрольлек (күзәтчелек) чарасын уздыруда
катнашучы вазыйфаи зат (затлар)

____________________________________________ ________________________
__________________________________________ ________________________
(имза)

Инспекторлар төркеме җитәкчесе (булган очракта)

__________________________________________ ________________________
(имза)